КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 декабрь г.Казань № 1288

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 22 июль, 613 нче; 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы; 2020 ел, 11 июль, 575 нче; 2020 ел, 19 август, 710 нчы; 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы; 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы; 2021 ел, 6 декабрь, 1168 нче; 2022 ел, 22 апрель, 389 нчы; 2022 ел, 1 июнь, 511 нче; 2022 ел, 18 август, 852 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 946 нчы, 2022 ел, 1 ноябрь, 1165 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

йөз егерме алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяли;

Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында каралган эшчәнлек өлкәсендә билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин